**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СПАССКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
СПАСС
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12 2022 ел Болгар ш. № 803

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 2 июлендәге 407 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә физик һәм юридик затларны мәгълүмати тәэмин итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Физик һәм юридик затларны Россия Федерациясе Архив фонды документлары һәм башка архив документлары нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, ТР Спас муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 2 июлендәге 407 номерлы карары белән расланган архив белешмәләрен, архив белешмәләрен һәм архив документларының күчермәләрен тапшыруны түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 2.8.2 пунктындагы 3 пунктчасын төшереп калдырырга.

1.2. 2.10 пунктының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында " 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган тапшыруда катнашучы, муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге.».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Спас муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

ТР Спас муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе В. А. Осокин